СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА
МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ                    КАРАР

15 нче декабрь, 2023 ел     Алабуга шәһәре     № 304

**Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советынвң «Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турында Нигезләмәне раслау хакында» 2023 елның 7 сентябрендәге 277 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында» 2020 елның 31июлендәге 248-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, Алабуга шәһәр прокуратурасының тәкъдименнән чыгып, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Советының 2023 елның 7 сентябрендәге 277 номерлы карары нигезендә расланган, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертеп, әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта нигезендә, түбәндәге редакциядә бәян итәргә.

«Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында муниципаль торак контролен гамәлгә ашырганда планнан тыш тикшерүләр үткәрү кирәклеген билгеләү өчен кулланыла торган мәҗбүри таләпләрне бозу куркынычы индикаторлары».

1). Муниципаль торак фондының торак бинасы булган күпфатирлы йортта, көн тәртибендәге шундый ук мәсьәләләр буенча карарлар булган, милекчеләрнең гомуми җыелышының ике һәм аннан да күбрәк беркетмәсенең өч ай рәттән муниципаль торак контроле органына керүе.

2). Дәүләт торак күзәтчелеге органына, муниципаль торак контроле органына гражданнардан (мөрәҗәгать иткән гражданның шәхесен билгеләргә мөмкинлек бирә торган ысул белән килгән) яки бина хуҗалары булган оешмалардан алдагы календарь елның шул ук чоры белән чагыштырганда, вакыт берәмлегендә (ай,

квартал) мөрәҗәгатьләр санының күп фатирлы йортта яшәүче гражданнар, күпфатирлы йорттагы биналарны кулланучылар, дәүләт хакимияте органнарыннан алынган мәгълүматның, җирле үзидарә органнары, массакүләм мәгълүмат чараларыннан, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Россия Федерациясе Торак кодексының 20 статьясының 1 өлешендә билгеләнгән мәҗбүри таләпләрне бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан контрольдә тотучы затлар тарафыннан бозу фактлары турында дәүләт мәгълүмат системаларыннан өч тапкыр һәм аннан да күбрәк артуы;

3). Россия Федерациясе Торак кодексының 165 статьясындагы 5 өлеше нигезендә, билгеләнгән урнаштыру тәртибе, рәвешләре, сроклары һәм вакыты нигезендә торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиешле мәгълүматны өч һәм аннан артык ай дәвамында актуальләштерүнең булмавы;

4). Бердәм диспетчерлык хезмәте мәгълүматы буенча, тикшерелә торган зат идарәсендә булган күпфатирлы йортта гомуми милекнең төзексезлеген бетерү эшләрен уздыру өчен ремонт бригадаларын атнага биш очрактан да артык чакыру;

5). Торак-коммуналь хуҗалыкның дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү документларында күпфатирлы йорт милекчеләренең гомуми мөлкәтен файдаланганда һәм тотканда кулланыла торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләмен алдагы шундый ук исәп-хисап чоры белән чагыштырганда 50% тан артык арттыру турында белешмәләрнең ачыклануы.»

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль корылыш һәм депутат этикасы мәсьәләләре буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Р.М. Нуриев